Хәерле көн, хөрмәтле Анатолий Петрович, президиум, авылдашлар!

*Яңа уку елына әзерләнгән вакытта узганына нәтиҗә ясау мөһим бер шарт булып тора.*

*Бүген белем сыйфаты турыдан-туры педагогик кадрларның хәзерлек дәрәҗәсенә бәйле. Һөнәри осталыгыңны көн саен шомарту, үз белемеңне даими баету һәм тирәнәйтү юнәлешендә эшләргә кирәклеген белә безнең укытучылар. Чөнки 21 гасыр укытучысы һәр укучының уңышлы шәхес булып җитешүе өчен җаваплы. Уңышлы кеше - ул безнең киләчәгебез. Ә уңышның башы - сыйфатлы белем.*

*Мәктәптә барлыгы 18 педагогик хезмәкәр эшли. Барысы да югары белемле. 8 укытучы- югары , 8 укытучы 1 квалификацион категориягә ия. Укытучыларыбыз иҗади үсештә. Алар даими рәвештә һөнәри бәйгеләрдә катнашалар. Узган уку елында башлангыч сыйныф укытучысы Эльмира Фәйзрахманова "Киләчәк укытучысы" республика конкурсы җиңүчесе, Гүзәл Валиева "Воспитать человека - 2020" республика конкурсының зона этабы җиңүчесе булды. Бу уку елында иң зур шатлыгыбыз – рус теле укытучысы Фазылова Резеда Фатхрахмановна "Татарстан Республикасының атказанаган укытучысы" исемен алды.*

2019-2020 нче уку елында МБГБУ "Усали урта гомуми белем мәктәбе"ndә барлыгы 7 авылдан 62 бала белем алды. Бу алдагы уку елы белән чагыштырганда 4 балага азрак.

Башлангыч классларда – 8 класс/ 5 комплект, 19 бала;

Урта өлештә - 5 класс, 27 бала;

Югары өлештә – 2 класс, 16 укучы.

**Уку эшчәнлеге күрсәткечләре**

| уку елы | өлгереш | сыйфат | өлгереш | сыйфат | өлгереш | сыйфат | өлгереш | сыйфат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2-11 | | 2-4 | | 5-9 | | 10-11 | |
| 2017-2018 | 100 | 58 | 100 | 65 | 100 | 46 | 100 | 80 |
| 2018-2019 | 100 | 58,85 | 100 | 71,43 | 100 | 41,94 | 100 | 63,64 |
| 2019-2020 | 100 | 67,8 | 100 | 75 | 100 | 55,56 | 100 | 81,25 |

**Профильле укыту**

| **Профиль** | **класс** | **укучы саны** |
|---|---|---|
| Химия-биология | 10 | 6 |
| Химия-биология | 11 | 10 |

2019-2020 нче уку елында мәктәпне 10 укучы тәмамлады. 2 укучы имтиханнарны уңышлы биреп, "За особые успехи в учении" медале алды.

*Дәүләтнең йомгаклау аттестациясе – белем сыйфатын объектив бәяләүче чара. Мәктәбебез район мәктәпләре арасында алдынгылар рәтендә бара.*

## БЕРДӘМ ДӘҮЛӘТ ИМТИХАННАРЫ

| предмет | 2018 | | 2019 | | 2020 | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | район | мәктәп | район | мәктәп | район | мәктәп |
| Рус теле | 77,6 | 79,4 | 74,22 | 94 | | 76,5 |
| Математика (профиль) | 60,4 | 67 | 63,25 | 80 | | 56,66 |
| Матем база | 4,7 | 5 | | | | |
| Физика | 57 | 54 | | | | 80 |
| Биология | | 68 | | | | 65,5 |
| Җәмгыять белеме | | 88 | 61,23 | 92 | | 56 |
| Химия | 72,62 | 69 | | | | 82 |
| Тарих | 61 | 65 | 59,3 | 65 | | |

*Югары балл җыючылар*

| *Исемлек* | *Рус теле* | *Физика* | *Химия* |
|---|---|---|---|
| *Зайнуллина Л* | *87* | | |
| *Кирушин В* | *82* | *80* | |
| *Шарифуллин И* | *91* | | *100* |

*Күрсәткечләр район һәм республика нәтиҗәләреннән югары . Бу - мәктәп коллективының сыйфатлы эш нәтиҗәсе. Алдагы еллардан тупланган мәгълуматларга күз салсак, мондый эш нәтиҗәбез беренче генә түгел.*

*Медалистлар*

| *2017-2018 нче уку елы* | *2018-2019 нчы уку елы* | *2019-2020 нче уку елы* |
|---|---|---|
| *1* | *1* | *2* |

9 нчы сыйныфны барлыгы 8 укучы тәмамлады. Барысы да аттестат алдылар. Бер укучы төп мәктәп курсын гел “5” ле билгеләренә генә тәмамлады.

## 2017-2018 нче уку елында ТДИ нәтиҗәләре

| предмет | Барлык укучы | «5» | «4» | «3» | «2» | өлгереш | сыйфат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Математика | 12 | 2 | 10 | - | - | 100 | 100 |
| Рус теле | 12 | 8 | 4 | - | - | 100 | 100 |
| Биология | 9 | 1 | 3 | 4 | - | 100 | 50 |
| Химия | 4 | 2 | 2 | - | - | 100 | 100 |
| География | 8 | 6 | 1 | 1 | - | 100 | 87 |
| Физика | 2 | - | - | 2 | - | 100 | 0 |
| информатика | 2 | - | 2 | - | - | 100 | 100 |

## 2018-2019 нчы уку елында ТДИ нәтиҗәләре

| предмет | Барлык укучы | «5» | «4» | «3» | «2» | өлгереш | сыйфат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Математика | 11 | 3 | 7 | 1 | - | 100 | 80 |
| Рус теле | 11 | 3 | 4 | 4 | - | 100 | 60 |
| Химия | 3 | 2 | 1 | - | - | 100 | 100 |
| География | 11 | 6 | 4 | 1 | - | 100 | 90 |
| Физика | 2 | - | 2 | - | - | 100 | 100 |
| Информатика | 6 | - | 5 | 1 | - | 100 | 82 |

9 сыйныфны тәмамлаган 4 укучы ССУЗ га укырга керде.

Уку елы дәвамында мәктәп укучылары фән олимпиадаларында, төрле дәрәҗәдәге бәйгеләрдә, конкурсларда катнашып, призлы урыннар яуладылар.

Фән олимпиадалары:

| дәрәҗәсе | предмет | класс | укытучы | җиңүче | призер |
|---|---|---|---|---|---|
| Район туры | Рус теле | 9 | Исмагилова А.Р. | | 1. |
| | Биология | 11 | Мухаметзянов З.С. | 1 | |
| | Биология | 10 | Мухаметзянов З.С. | | 1 |
| | Физика | 11 | Хусаинова Р.В. | | 1 |
| | Математика | 5 | Сабирзянова Л.Я. | 1 | |
| | Татар теле | 4 | Хисамутдинова С.М. | 1 | |
| | Татар теле | 4 | Хисамутдинова | | 1 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | С.М. | | |
| | Татар теле | 5 | Насибуллина Г.Х. | 1 | |
| | Татар теле | 5 | Насибуллина Г.Х. | | 1 |
| | Татар теле | 5 | Насибуллина Г.Х. | | 1 |
| | Татар теле | 5 | Насибуллина Г.Х. | | 1 |
| | Татар теле | 6 | Хайбуллина З.Г. | 1 | |
| | Татар теле | 6 | Хайбуллина З.Г. | | 1 |
| | Татар теле | 7 | Насибуллина Г.Х. | | 1 |
| | Татар әдәбияты | 9 | Хайбуллина З.Г. | | 1 |
| | Татар теле | 10 | Хайбуллина З.Г. | 1 | 1 |
| | Татар теле | 11 | Насибуллина Г.Х. | | 1 |

2019-2020 нче уку елында методик эш укытучыларның компетентлыгын күтәрү юнәлешендә алып барылды: методик берләшмәләр, педагогик киңәшмәләр, атналыклар, һөнәри конкурсларда катнашу формаларында эш оештырылды. Ноябрь аенда тарих укытучылары, февраль аенда рус теле укытучылары, укыту-методик эшләр буенча директор урынбасарлары семинарлары узды. Укытучылар ачык дәресләр, ачык чаралар күрсәтте. Алдынгы тәҗрибә белән уртаклаштык

Мәктәптә барлыгы 4 методик берләшмә эшләде: класс җитәкчеләре, башлангыч сыйныфлар, гуманитар фәннәр, математика фәннәре. Берләшмә утырышларында сәләтле балалар белән эшләү, олимпиадаларга әзерләү, БДИ һәм яңа форма имтиханнарга әзерлек, ФГОС, яңа технологияләрне өйрәнү һәм укыту-тәрбия эшенә кертү һ.б. проблемалар каралды. Педагогик киңәшмә утырышларында укучыларның БДИ һәм ГИА га әзерләнүен оештыру, Электрон белем бирү, ФГОС буенча дәрескә куелган таләпләр турында фикер алышу булды. Сәләтле балалар, авыр үзләштерүчеләр белән эш оештыруга зур игътибар бирелде.

Укытучыларның белемен, категориясен күтәрү буенча эш дәвам итте. 2019-2020 нче уку елында 5 укытучы курсларда булды. 1 укытучы югары категориягә үз категориясенаклады

**У**кучыларның тәрбиялелеге - белемлелек сыйфатын бәяләүче критерий булып тора. Мәктәпнең тәрбия өлкәсендә рейтинг нәтиҗәләре буенча район мәктәпләре арасында алдынгы урында торуы очраклы түгел. Белем бирү белән тәрбия эше бездә бергә үрелеп бара.

Яшь буынны тормышка әзерләү, аңа сыйфатлы белем-тәрбия бирү дәүләтнең мәктәп алдына куйган төп бурычы.

Безнең Үсәли урта гомуми белем бирү мәктәбендә 2020-2021 нче уку еллында барлыгы 50 бала белем ала. 1 нче яртыеллыкка уку сыйфатыбыз- 67% тәшкил итә.

Мәктәптә 17 югары белемле укытучы эшли. Шуларның 8 – югары, 8 – беренче категориягә ия. Укытучылар төрле конкурсларда актив катнашып , югары нэтиҗәләр курсәтәләр. Тырыш һәм нәтиҗәле хезмәте өчен рус теле һәм әдәбияты укытучысы Фазылова Резеда Фатхрахмановна “Татарстаннын атказанган укытучысы” исеменә лаек булды. Тәрбия эшләре буенча директор урынбасарыбыз Валиева Гүзәл Миннулловна “Иң яхшы тәрбия эшләре җитәкчесе”, “Воспитать человека” һөнәри осталык конкурсының зона этабы җиңүчесе , башлангыч класс укытучысы Аксакова Гүзәлия Шәйхатдаровна Татарстан

Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы грамотасына лаек булды, укыту эшләре буенча директор урынбасарыбыз Хайбуллина Зөбәрҗәт Габделхаковна Россия Федерациясе мәгариф һәм фән министрлыгының мактау грамотасы белән бүләкләнде .Константинова Лидия Семеновна "Мәгариф" журналы оештырган күпләгән конкурсларның җиңүчесе булды.

Мәктәпнең эш алымнарын өйрәнү, эш тәҗрибәсен тарату максатыннан узган уку елында тарих укытучыларының "Балаларга белем һәм тәрбия бирүдә дәрестән тыш эшчәнлекнең роле", рус теле укытучыларының "Дәресләрдә яңа технологияләр куллану", укыту эшләре буенча директор урынбасарларының "ФДББС" күчеш чорында дәрес һәм дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру" дигән район семинарлары узды.

Узган уку елы барыбыз өчен дә зур сынау булды. Уку елын дистанцион рәвештә йомгакларга туры килде

Укытучының эш нәтиҗәсе, нинди генә очракта да, укучыларының өлгереше белән бәяләнә. Сыйфатлы белем һәм тәрбия бирү - иң мөһим күрсәткечебез. Нәтиҗәләребез экранда чагылыш таба.

Укучыларыбыз дәүләт имтиханнарын уңышлы тапшыралар. Нәтиҗәләребез район, республика күрсәткеченнән югары. Химия фәненнән 1 укучы 100 балл нәтиҗә курсәтүе зур сөенеч булды.

Мәктәпне "Укудагы казанышлары" медаленә тәмамлаучы укучыларыбызның ел саен булуы мәктәптә укыту-тәрбия эшенең тиешле югарылыкта булуын исбатлый.

Укучыларыбыз ел саен фән олимпиадаларында актив катнаша.2020-2021 уку елында ,район кулэмендэ 10 призерыбыз һәм жинучебез бар. Җиңүчеләр –математикадан, экология һәм рус теленнән, 3 укучы – татар теленнән. 2020 нче ел нәтиҗәләре буенча Терентьев экологик конференциясендә 1 укучы призер булды. Балаларыбыз район , республика кулэмендэ уткэрелэ торган башка чараларда да актив катнашып . жину һәм призлы урыннарны яуладылар..

Мәктәпне тәмамлаганнан соң укучыларыбыз укуларын республикабызның төрле уку йортларының бюджет бүлекләрендә дәвам итәләр.

II. Уку һәм тәрбия игезәк туганнар кебек. Аның нәтиҗәсен бер генә көндә күрергә дә, бәяләргә дә мөмкин түгел. Рухи-әхлакый кыйммәтләр, тарихи һәм милли-мәдәни традицияләр нигезендә гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү - безнең максатыбыз.

Укучыларның иҗади сәләтләрен ачу, алга таба үстерү мәктәптән тыш эшләр, түгәрәкләр аша алып барыла. Укучыларның барысы да үзләре теләгән түгәрәкләрдә шөгылләнә.

Укучыларбыз торле акциялэрдэ хэм конкурсларда катнашып призлы урыннар яулыйлар. Район кулэмендэ узган "Созвездие" конкурсында Шарифуллина Нәфисә, Исмагилова Фирүзә, Абдуллина Алинә, Гилязов Раделләр уңышлы чыгыш ясадылар. , "Диана Мишкина" исемендәге V регионара фестивальдә "Сәйлән" фольклор ансамбеле 1 нче урынны яулады. Гармунчы егетләребез , фольклор ансамбелебез булуы белән горурланабыз. Кайда гына чыгыш ясасалар да мактау сүзләре, грамота-дипломнар белән кайталар. ТНВ каналы гармунчылар ансамбеле хакында махсус тапшыру әзерләде.

Мәктәп экологик белем һәм тәрбия бирү буенча район, республика куләмендәге чараларда актив катнаша.Шушы юнәлештә мәктәп базасында район семинары үтте. Экологик эшчәнлек белән күргәзмәләрдә катнашабыз. Алдагы елларда мәктәбебезнең "Азбука Земли" командасы "Будет чисто" яшьләр оешмасының экологик эшчәнлеге буенча Мамадыш районында төп координаторлары булып торды. "Эковесна " конкурсының республика

этабында катнашып “Ин яхшы мәктәп” исеменә лаек булган идек. Ә 2019-2020 нче ел йомгаклары буенча, республика күләмендә узган “Яшел (зеленая) эстафета” конкурсында I урынны яуладык. “Актив года “ конкурсында Гран-прига лаек булдык. “Яшь көч” балалар оешмасы да район, республика күләмендә оештырылган барлык чараларда актив катнашып, III урынга чыктык. Профилактика отрядының да эше уңай яктан бәяләнде.Гомуми нәтиҗәләр буенча тәрбия эшен оештыру өлкәсендә , авыл мәктәпләре арасында, безнең Үсәли урта мәктәбе беренче урынга чыкты.

Патриотик тәрбия эше дә системага салынган. Мәктәптә “Туган як” музеебыз бар. Хәрби таприотик айлык зур оешкан төстә уза. Ел дәвамында район, республика күләмендә оештырылган чараларда актив катнашып, мактау грамоталарына лаек булдык. Патриотик темага класс сәгатләре, тәрбия минутлары оештырылды. Бөек жинугә 75 ел булуы унаеннан авыл жирлеге, мәдәния хезмәткәрләре һәм мәктәп коллективы белән берлектә сугыш ветеранбыз Миргазиз абый Ситдиков , тыл ветераннары белән, тиешле таләпләрне саклап, очрашулар, котлау акцияләре оештырдык.

Һөнәр сайлау, профориентация эшчәнлегенә дә зур игътибар бирәбез. Район башлыгыбыз Анатолий Петрович Иванов инициативасы нигезендә эшләп килүче “Тормыш дәресләре” проектында мәктәбебез яхшы нәтиҗәләр күрсәтә .

Мәктәптә спортка, балаларның сәләмәтлегенә зур игътибар бирелә. Инде 11 ел рәттән “Өмет стартлары” кысаларында узган ярышларда призлы урыннан төшкәнебез юк. “Олимпиада -100” проектында да сынатмыйбыз. (3кл-1, 10-2 урында).Укучыларыбыз арасыннан алдагы елда Сидорова Оксана, Кирушин Виталий “Спорт остасына кандидат” нормативын үтәделәр.

Территориябездэ күпфункцияле мэйданчык бар. Анда төрле ярышлар уткэрэбез. Бу мэйданчык уку вакытында гына тугел, жэйге хэм кышкы каникуллардада балаларнын да, студентларның да яраткан уен урыннары булып тора. Хормэтле Анатолий Петрович , безгэ мондый момкинлеклэр тудырганыгыз очен безнен авыл жирлегенэ, мэктэбебезгэ хэр даим ярдэм итуегез очен барлык коллектив исеменнэн бик зур рэхмэт сезгэ!

Мәктәптә хезмәт тәрбиясенә дэ зур игътибар бирелә , бизнес- план эшләп килә. Узган уку елында (3 га бәрәнге, 20 сотый чөгендер,20 сотый кишер, 20 сотый кәбестә, 7 сотый суган, үстерелде) барысы 728868 сумлык уңыш җыеп алынды. Бер балага 14577,37 сум акча эшләнелде. Аның бер өлеше сатылды,бер өлеше семенага салынды,бер өлеше балаларга ашату өчен кулланыла. Үзебез эшләгән акчаны мәктәптә төрле бәйрәмнәр, кичәләр үткәрү өчен, мисал өчен уңыш бәйрәме, яңа ел кучтэнэчлэре алу өчен һәм мәктәпне материаль яктан ныгыту өчен тотабыз.

Мәктәптә 5-11сыйныфларга ике мәртәбә кайнар ашату оештырыла, уртача көнлек ашату 32 сум тэшкил итэ.Башлангыч сыйныф укучыларыбыз сентябрь аеннан бушлай кайнар ризык ашый. Дәүләт тарафыннан билгеләнгән әлеге ашау 51 сум 80 тиен тэшкил итэ. Башлангычлар дигәннән, балалар төрле авыллардан килә. 7 дә өйдән чыгып китәләр. Обед вакытына кадәр тамаклары ача. Шуны исәптә тотып, мәктәп исәбеннән, башлангычларны да ике тапкыр ашатабыз.

Мэктэбебездэ тозеклэндеру эшлэре дэ тукталмады  Котельная  түбәсен  мягкая кровля белән яптык ,коймаларны  профнастил куеп  тозеклэндердек.  Мәктәпкә косметик ремонт үткәрелде .

Мәктәпне тәмамлаган укучыларыбызның ярдәмен тоеп яшибез. Газизов Фәннур Фатхуллович  ремонт эшләре вакытында ярдәм итсә, Хисматуллин Илгизәр Нуриахметович балаларны Яңа ел бүләкләре белән сөендерде. Депутатыбыз Смирнов Игорь Владимирович ел саен  Кыш бабай  капчыгын  тәм –томнар белән  тутыра.  Балалар, әти-әниләр, укытусылар коллективы исеменнән аларга зур рәхмәтебезне  җиткерәбез.

Мэктэбебездэ укудан кала балаларны ял итттеру, кызыксындыру чаралары да оештырылган. Укучыларбыз экскурсиягэ район музеена бардылар. Кышкы каникул чорында Казанга экскурсия оештырылды. Районыбыз колледжына, алдагы елларда Алабуга экономик зонасына барып,  торле профессиялэр белэн таныштылар.Мондый момкинлеклэр тудыручы, районыбыз башлыгы Анатолий Петровичка, Мәгариф бүлеге житэкчесе Ильдус Нурисламовичка зур рэхмэтебезне белдерэбез. Алга таба ,  мәктәп эшендә актив катнашкан 2 классны  Тукай Кырлайга алып  бару хыялы  бар.

Нәтиҗә, планнар  бар икән, димәк  мөмкинлек бар,  белем алу өчен шартлар  тудырылган дигән сүз.  Мәктәпкә 6 ел элек капиталь ремонт булган иде. Бездә җылы, якты .  Менә ашханәбез  капиталь ремонтка кертелде. Боларның барысы өчен район башлыгыбыз Анатолий Петровичка  рәхмәтебез зур.

Сүземне йомгаклап: киләсе елларда да уңышларыбыз  сөендерсен, тотрыклы  белем  алу өчен мәктәпләрнең материаль-техник базасы бай, белем-тәрбия алу мөмкинлекләребез киң, киләчәк юлыбыз туры, кыйблабыз нык булсын.

Барчагызны  саулык, сәламәтлек, эш дәрте, күңел тынычлыгы телим.Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт.